СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 2А, д.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2А йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)5-07-35, факс (843665-07-35). E-mail: Sat.Ars@tatar.ru

**Урта Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№ 101** **“21” август 2019 ел**

**Урта Аты авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 48 номерлы «Җир салымы турында " карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31 бүлек, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Уставы нигезендә Урта Аты авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Урта Аты авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 48 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

-2 нче пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент.”

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан гына үз көченә керә.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Батталова